# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

«12» декабрь 2016 ел № 11/5

**Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, район Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар район Советының 2016 елның 21 ноябрендәге «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 10/4 номерлы карары теркәлгәннән соң, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән дә иртәрәк түгел, үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

М Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев